Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № ХХ-6**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 24 июле

“Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә аларны биләгәндә муниципаль хезмәткәрләр керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырырга тиеш булган муниципаль хезмәт вазыйфаларының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге Х-4 номерлы карары белән расланган исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

“Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8, 8.1 маддәләре, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 маендагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе, “Федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында” 2009 елның 18 маендагы 559 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 маддәсе, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре аларны биләгәндә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында" ПУ-701 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар бирү турында” 2009

елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә аларны биләгәндә муниципаль хезмәткәрләр керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырырга тиеш булган муниципаль хезмәт вазыйфаларының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге Х-4 номерлы карары белән расланган исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең 4 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Башкарма комитет бүлегенең, секторының, органының әйдәүче белгече.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев